# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«30» 06 2021 ел Яр Чаллы № 1732

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30-34 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, РФ Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы, Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 26 июнендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында» 1790 номерлы карарының 3.1 пункты нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын эшли башларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эш башкару тәртибен һәм срокларын расларга.
3. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 306 каб. адресы буенча җибәрелә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин